# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

07 08 2026 ел Яр Чаллы ш. №2705

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 маендагы 1422 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алуда гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 19 июлендәге 204-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына линия объектларын урнаштыруны гадиләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 03 августындагы 341-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 маендагы 1422 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.1 пункты 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән:

1) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, әлеге Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү әлеге Федераль законның 16 статьясы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса мөмкин;

3) мөрәҗәгать итүчедән тапшыруы яки гамәлгә ашыруы дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документларны яки мәгълүмат яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары норматив

хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү әлеге Федераль законның 16 статьясы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса мөмкин;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, күп функцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү әлеге Федераль законның 16 статьясы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса мөмкин;

8) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) әгәр федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү әлеге Федераль законның 16 статьясы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса мөмкин;

10) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда документларның яисә мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны таләп итү, әлеге Федераль законның 7 статьясы 1 өлеше 4 пункты белән каралган очраклардан тыш. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан

тыш) шикаять бирү әлеге законның 16 статьясы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса мөмкин.».

1.2. 2 бүлекнең 2.9 статьясы 4 пунктчасына сүзләр өстәргә:

«әгәр мондый яңадан бүлү әлеге Кодексның әлеге 27 статьясы 5 пункты 7 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләре белән территорияне ызанлау проекты нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш».

1.3. 2 бүлекнең 2.9 статьясы 3 пунктчасында:

«әлеге Кодексның 39_36 статьясы 3 пунктында каралган һәм җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануга комачауламаган сервитут яки объект шартларында урнаштырыла торган» сүзләрен «урнаштыру сервитут, гавами сервитут яки әлеге Кодексның 39_36 статьясы 3 пункты нигезендә урнаштырылган объект нигезендә рөхсәт ителә торган» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И.М. Минимуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов